| СОВЕТ<br>Кучуковского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Көчек авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.05.2022 Түбән Көчек авылы № 17-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 декабрендәге 13-1 номерлы карары белән расланган 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Советы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 декабрендәге 13-1 номерлы карары белән расланган 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге бюджетына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Ә.Нурмөхәммәтов

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Көчек авыл җирлеге Советының
2021 елның 17 декабрендәге 13-1 номерлы
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 декабрендәге 13-1 номерлы карары белән расланган 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге бюджетына үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 декабрендәге 13-1 номерлы карары белән расланган 2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге бюджетына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяны төшереп калдырырга:

«4 Статья

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге бюджетының 2022 елга һәм 2023, 2024 елларның план чорына керемнәренең Баш администраторлары исемлеген (№5 кушымта) расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген (№6 кушымта) расларга. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты, башкарма хакимият органнары функцияләре үзгәргән очракта, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге бюджетының әлеге статьяда каралган төп керем чыганакларын һәм финанслау чыганакларын анnetwork ыкларга хокуклы.».

1.2. Бюдңетка 5 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

1.3. Бюджетка 6 нчы кушымтаны төшереп калдырырга.

1.4. 13 статьяда бишенче абзацны төшереп калдырырга: «Әлеге статья таләпләрен бозып төзелгән килешү яисә аның Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге бюджетының артык йөкләмәләрен билгеләүче өлешен яклар килештереп яисә югары оешма яисә Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы дәгъвасы буенча суд карары нигезендә, гамәлгә яраксыз дип, танылырга мөмкин.».